СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2019 г. Заинск № 412

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Советының 2016 елның 26 августындагы 115 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләре, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль район Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Зәй муниципаль район Советының 2016 елның 26 августындагы 115 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2.23 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак биналарда сәнәгать производстволарын урнаштыру, шулай ук миссионерлык эшчәнлегенең торак урыннарында, «Вөждан иреге һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында каралган очраклардан тыш, урнаштыру рөхсәт ителми.»;

1.2. 3.2.29 пунктында «чикләр» сүзен төшереп калдырырга;

1.3. 4.1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак пунктлар җирләренә урман фонды җирләрен яисә җир кишәрлекләрен күчерү Россия Федерациясе Урман кодексы, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» Федераль Законы, «Урман фонды җирләрен башка (башка) категорияләргә күчерү турында документлар составы һәм әзерләү тәртибе турындагы Нигезләмә» нигезендә генә рөхсәт ителә. «Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 4 декабрендәге 201-ФЗ номерлы Федераль законының 9 статьясы нигезендә урман фонды җирләрендә гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек территорияләрен урнаштыру, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару, шәхси гараж яки шәхси торак төзү өчен урман кишәрлекләре бирү тыела.»;

1.4. 4.3.12 пунктның алтынчы абзацында «балык саклау зоналары» сүзләрен «Байкал күле балык саклау зонасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 6.3.20 пунктында:

1.5.1. 1 нче пунктчада:

а) беренче абзацта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

в) өченче абзацта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

1.5.2. 2 пунктчада «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

1.1. 6.3.21 пунктта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

1.7. 6.3.25 пунктта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

1.8. 6.3.31 3 пунктта «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

1.9. 8 нче кушымтада:

а) 1 таблицада «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 таблицада «(урман паркларында)» сүзен төшереп калдырырга.

2. Зәй муниципаль район Советы оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**